**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы № 53 «14 » 04 2017 ел

2016 ел өчен Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районының Чемодурово
авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында 2016 елгы хисапны керемнәр буенча 11 356,8 мең сум һәм чыгымнар буенча 11 472,7 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 115,9 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга::

1) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты керемнәре;

2) әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

3) әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

4)Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Рәис Н.Б. Котельникова